**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023елның апрель 03 1147 номер

# КАРАР

## Җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын тартып алу турында

Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 145 номерлы карары белән расланган 2019-2023 елларга Лаеш муниципаль районындагы авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны Татарстан Республикасы «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында»2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Күп фатирлы торак йортларны авария хәлендә дип тану турында» 2011 елның 30 декабрендәге 2286 номерлы Башкарма комитет карары белән Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен кадастр номеры 16:24:240101:2729 булган, гомуми мәйданы 287,0 кв. м булган, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Сокуры авылы, Совет урамы, 49 йорт адресы буенча урнашкан авария хәлендәге торак йорт урнашкан җир кишәрлеген тартып алырга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авылында Совет урамындагы 49 нчы авария хәлендәге торак йортның, 16:24:240101:1353кадастр номерлы гомуми мәйданы 41, 9 кв. м булган, 1номерлы фатирын муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алырга.

3. Бу карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә:

- әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–

адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

- әлеге карарның күчермәсен күчемсез милеккә хокукларны теркәүне гамәлгә ашыручы органга җибәрергә.

- әлеге карарның күчермәсен һәм торак бинаны тартып алу турында килешү проектын аның хуҗасына (милекчеләренә)җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче**
**вазыйфаларын башкаручы** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**